СОВЕТ
КАЧЕЛИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Центральная , д. 200, с.Качелино,
Арский муниципальный район, 422013

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КӘЧЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Үзәк урамы, 200 йорт, Кәче авылы,
Арча муниципаль районы, 422013

Тел. (84366)52-3-93, факс (84366)52-3-93. E-mail: Kach.Ars@tatar.ru

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Кәче авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Башлыгы**
**КАРАРЫ**

**«01» ноябрь 2024 ел. № 2**

**Арча муниципаль районы Кәче авыл җирлеге Чулпан авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль Кәче авыл җирлеге Уставының 25 статьясы нигезендә, Арча муниципаль районы Кәче авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Башлыгы Карар бирде:

1. Арча муниципаль районы Кәче авыл җирлеге Чулпан авылында Чулпан авылы, Гагарин урамы, 7а йорты адресы буенча гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча 2024 елның 15 ноябренә 14 сәгать 00 минутта халык җыенын билгеләргә.

2.Халык җыенына чыгарылучы түбәндәге мәсьәләне расларга:

«Сез 2025 елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы Кәче авыл җирлеге Чулпан авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, түләү күләме 75 сум тәшкил иткән көндезге формада укучы студентлардан, 75 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан тыш, 150 сум күләмендә үзара салым кертү, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны һәм аларның гаилә әгъзаларын (бергә яшәүче ата-аналарын, хатынын, балигъ булган балаларын) түләүдән азат итү һәм җыйналган акчаның түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә тотылуына сез ризамы?

-торак пункт чикләрендә гомуми файдаланулагы җирле әһәмияттәге, автомобиль юлларын төзү,ремонтлау, тоту (Чулпан авылының Ерганак, Тимер юл урамында юл полотнасын ямау юлы белән төзекләндерү).

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, авыл җирлеге башкарма комитетына акчаны җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен җибәрергә рөхсәт итәргә.

“ӘЙЕ” “КАРШЫ”»

3.Арча муниципаль районы Кәче авыл җирлеге Чулпан авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын оештыручы итеп Кәче авыл җирлеге башкарма комитетын билгеләргә.

4.Әлеге карарны халык күп җыела торган урыннарда мәгълүмат стендында: ТР, Арча районы, Чулпан авылы, Гагарин урамы, 7а йорты адресы буенча, интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Арча муниципаль районының рәсми сайтында http://arsk.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы Рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Кәче авыл җирлеге башлыгы Р.Р. Гәрәев